**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының**
**Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

**№ 119** **«21» сентябрь 2018 ел**

**«Гражданнарның үзара салымы турында нигезләмә хакында» 2014 елның 20 февралендәге 76 номерлы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. «Гражданнарның үзара салымы турында нигезләмә хакында» 2014 елның 20 февралендәге 76 номерлы Сармаш-Баш авыл җирлеге Советы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:
1.1. II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 6 пунктны өстәргә:
«6. Гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе авыл җирлеге башкарма комитеты кабул итә торган муниципаль хокукый акт белән билгеләнә.»;
1.2. III бүлекне төшереп калдырырга.
2. Карарны Сармаш-Баш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе,**
**авыл җирлеге башлыгы** **Р.М. Фәсхетдинов**